ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ГАЙТӘН АВЫЛЫ СОВЕТЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ГАЙТАНКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

423014, РТ, Нурлат районы, Гайтән авылы, Үзәк ур., 1нче йорт
Тел. 8 (84345) 3-98-01

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» октябрь 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлегенең Кәкре Атау авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гәйтән авыл җирлеге Уставының 23нче маддәсенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Гәйтән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык буенча 2нче йортта Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча 1-68нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 2019 елның 14 ноябрендә 18 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык буенча 2нче йортта Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Үзәк урамы буенча №69-124 нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын 2019 елның 19 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Гайтән авыл җирлеге Кәкре Атау авылында Үзәк тыкрык буенча 2нче йортта Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылында Кыр урамы буенча №1-59 нчы, Үзәк тыкрык буенча №1-14нче йортлардан үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын 2019 елның 24 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль буенча башкарырга.

5. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эше Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге башлыгы һәм башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлегенә Кәкре Атау авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм яшәүче балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, балачак инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш, 2020 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1) Кәкре Атау авылында су чыганагын норматив таләпләргә китерү буенча эшләр үткәрү.

2) Кәкре Атау авылы зиратын карап тоту.

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (игълан итәргә) http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Кәкре Атау авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга

8. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Гайтән авыл җирлеге башлыгы Н. В. Авдеева